**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КАРАТУН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

2020 ел, 1 октябрь №6

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының «Каратун авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәрләренең, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләү турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 6 августындагы «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының айлык акчалата түләү күләмнәрен арттыру турында» 658 номерлы карарына таянып Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Каратун авыл җирлеге Советы карар бирә:

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Каратун авыл җирлеге Советының 2018 елның 5 апрелендәге «Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы «Каратун авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәрләренең, җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү турында» 122 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«2.Муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләме авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи оклады күләменә бәрмәбер исәпләнә. Шул ук вакытта авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладының күләме 11 498 сум тәшкил итә.»

2) 2 нче кушымтада таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| Вазифа атамасы | Акчалата түләү күләме (сум) |
|---|---|
| Авыл җирлеге башлыгы | 15759,00 |

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карар 2020 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

**Каратун авыл**
**җирлеге Башлыгы** **Р.Р. Сабирҗанова**